**“Туган якка мәдхия” Күренекле якташыбыз шагыйрә Фәүзия Мөхәммәтова белән очрашу кичәсенә сценарий.**

Эльмира Сабирҗан кызы Сәлахова, «Сәламәтлек мөмкинлекләре чикләнгән балалар өчен Нурлат мәктәп-интернаты» Дәүләт бюджет гомуми белем учреждениесенең югары категорияле татар теле һәм әдәбияты укытучысы.

Башлап җибәрү. Музыка яңгырый.

1 нче алып баручы.

Исәнмесез, кадерле кунаклар, укытучылар, тәрбиячеләр, укучылар!

Безнең Нурлат җире күренекле кешеләргә бай. Ә хәзер туган төбәгебез, аның талантлы кешеләре турында белемнәребезне барлап китик әле.

- Безнең Нурлат ягы нинди байлык белән данлыклы? (кара алтыны - нефть, уңдырышлы җире, ак шикәре белән данлыклы)

- Әйе, укучылар, Нурлат ягы хуш исле икмәге, ак шикәре, кара алтын ятмалары белән данлыклы.

Кара алтын ятмалары –
Табигать хозурлыгы.
Нурлатым хәзинәсе ул,
Нурлатым горурлыгы. – дип яза күренекле якташыбыз, шагыйрә Фәүзия Мөхәммәтова кара алтын – нефть турында

Әйе, укучылар нефть – туган ягыбызның хәзинәсе.

- Хәзинә - тирән мәгънәгә ия сүз. Беренчедән, ул - җир мае, байлык. Икенчедән, шушы байлыкны табучылар, хезмәт кешеләре үзләре дә хәзинә. Ә болардан башка тагын нинди байлык бар? (Җан байлыгы)

- Нәрсә соң ул җан байлыгы? ( Яхшы сүз, әдәби әсәрләр, җыр, китап, уй – фикер, рәсем, шигырьләр)

- Җан байлыгын кемнәр тудыра? ( язучылар, шагыйрьләр, композиторлар, артистлар, җырчылар)

Безнең Нурлат ягы кара алтыны белән генә түгел, шушы җан байлыгын тудыручылары күп булуы белән дә горурлана ала. Әйе, Нурлатымның алыштыргысыз байлыгы – аның бөек шәхесләре! Кемнәр соң алар – безнең бөек шәхесләребез! (слайдлардан)

Укучылар, сез бүгенге көндә туган җиребездә яшәп иҗат итүче нинди күренекле якташларыбызны (шагыйрьләребезне, композиторларыбызны, җырчыларны ) беләсез? Экранга күз салыйк әле.

Әйе, укучылар. Һәр якның, һәр төбәкнең бик матур кешеләре бар. Төскә - биткә генә түгел, үзләренең күркәм эшләре, тоткан кыйблалары белән киләчәк буыннарга да үзләреннән тирән эз калдырган шәхесләр яши. Алар мактанып йөрмиләр, тыныч кына эшлиләр, иҗат итәләр.

Безнең мәктәбебездә бик матур бер традиция бар. Без Нурлат җирендә иҗат итүче шагыйрьләр, язучылар, композиторлар, җырчылар, артистлар белән һәрдаим очрашулар үткәреп торабыз.

2 нче алып баручы.

“ Иңнәремдә тоям яшәү көчен,
Кулларымда сихри тылсым бар
Газиз туган җиргә, үз халкыма
Йөрәгемдә рәхмәт хисе бар”

1 нче алып баручы.

Бүген дә мәктәбебездә зур бәйрәм – очрашу кичәсе. Бүген бездә кунакта Татарстан Республикасы Язучылар берлеге әгъзасы, районыбызның «Ак калфак» татар хатын-кызлары иҗтимагый оешмасы җитәкчесе, барыбызга да таныш булган, якташыбыз шагыйрә Фәүзия апа Мөхәмматова. Фәүзия апа, рәхим итеп, Сезнең сәхнә түреннән урын алуыгызны сорыйбыз.

Шулай ук бүген бездә кунакта:

Район мәгариф идарәсенең милли мәсьәләләр буенча методисты Фәридә Минталип кызы Ярмөхәмматова.

Кичәбезне Фәүзия апа сүзләренә, шулай ук күренекле якташыбыз композитор Р. Мифтахов көй салган “Нурлатым, әй Нурлат” җыры белән башлыйбыз.

Җыр “Нурлатым, әй, Нурлат”

2 нче алып баручы.

Фәүзия апа Мөхәммәтова гаҗәеп матур табигатьле Якты Күл авылында туа. 20 яшенә кадәр ул туган авылында яшәп белем алган, шәфкать туташы һөнәрен үзләштергән.

1 укучы.

Туган ягым җанга газиз
һәр карыш җирең изге –
Балыннарың яшел келәм,
Күлләрең көмеш көзге.

2 нче укучы.

Якты Күлем күлләреңә
Аккошлар оя кора
Көмеш көзгедәй күлләрең
Үзе җыр сорап тора

1 нче алып баручы.

Иң гүзәл авылның берсе
Нурлы як төбәгендә.
Туган якка мәхәббәтем
Моң тулы йөрәгемдә.

Җыр “ Дусларым, дускайларым” Ф.Мөхәммәтова сүзләре, көе.

1 нче алып баручы.

Ф. Мөхәммәтова өчен инде Югары Нурлат авылы да бик газиз һәм бик кадерле төбәкнең берсе. Чөнки аның монда тулы канлы тормыш белән сугарылып 40 еллап гомере үтеп киткән. Ул монда гаилә корган, хәләл көчтә

мал мөлкәтен туплаган, яраткан хезмәте белән авылдашларына игелекле ярдәм күрсәтеп яшәү бәхетенә ирешкән һәм иң мөһимә - энҗе бөртегедәй өч кыз баласына да югары белем биргән һәм зур тормыш юлына озаткан, бүгенгесе көндә 5 оныгының яраткан әбисенә әйләнгән. Югары Нурлат авылы аңа иҗат җимеше дә биргән . Шушы авылда бар сәләтен эшкә җигеп, бер - бер артлы 9 китап язып, аларны дөньяга чыгарырга насыйп булды аңа. (Экранда Ф. апаның басылып чыккан китапларын күрәсез)

2 нче алып баручы.

Зур горурлык хисе кичереп Югары Нурлат авылы турында Фәүзия апа болай дип яза:

Исемең шөһрәтле,

Көдрәте бар кебек

Син яшәү чишмәсе –

Ышаныч һәм өмет

Югары Нурлатым

Син Өмет канатым

Бәхетнең олысын

Тик синдә, мин таптым

Үз кызың иткәнгә

Үз итеп яраттым!

1 нче алып баручы.

Фәүзия Мөхәммәтованың шигырьләре төрле темаларга караган. әниләргә, хатын – кызга, хезмәт кешесенә, мәхәббәткә. Ул үз иҗатына илһамны туган туфрактан, эчкән суларыннан ала. Туган ягының фирүзә күк йөзе, талгын җилләре, ай нурында коенган төннәре, сихри таңнары аны иҗатка илһамландыра. Шуңа күрәдәдер аның төп темаларыннан тагын берсе –туган якка мәдхия җырлау. Менә бүгенге очрашу кичәбездә дә, һәрберебез өчен кадерле булган туган ягыбызга мәдхия җырларбыз.

Читтә йөргән чакта, сагындырып

Керер өчен төнлә төшенә

Зәңгәр таңлы, биек, аяз күкле

Туган ягы кирәк кешегә.

Яшәү өчен бетмәс көч алырга

Олысына һәм дә кечегә

Мәхәббәтле, ямьле, мәрхәмәтле

Туган ягы кирәк кешегә

3 нче укучы.

Туган як һәркемгә изгедер,

Булганга, күрәсең, бер генә.

Үз туган җиреңдә яшәүнең

Кадерен бел генә, бел генә.

4 нче укучы.

Туган як –балачак мизгеле.

Туган як- яшлегем эзләре.

Туган як йөзендә чагылсын

Гомернең бәхетле көзләре.

5 нче укучы.

Туган як – табигать бүләге,

Гаҗәеп матурлык үзеңдә.

Илаһи бер кодрәт бар сыман

Зәңгәрсу чишмәләр күзендә.

6 нчы укучы.

Туган як ул-бәхет кояшы,

Яшәтер нигез һәм оябыз.

Туган як куенында гына без

Бәхетнең олысын оябыз.

1 нче алып баручы.

Җан сусавын басар моң-чишмә

Тула да, күңелдә ургылып,

Илаһи тылсымга әйләнә

Тагын бер өр-яңа җыр булып.

Сыйдырып бар серен галәмнең

Зәңгәрсу чишмәләр күзенә,

Табигать үзе дә буйсына

Тылсымлы җыр-моңның үзенә.

Җыр “Нур иле син, Нурлат” Ф.Мөхәммәтова сүзләре, Сәмигулла Рәхмәтуллин көе.

7 нче укучы.

Әкияткә тиң туган ягым-

Энҗе тәңкәле кышы.

Язларын кыштан аера

Аҗаганнар балкышы.

8 нче укучы.

Урманнары сихри-серле,

Яши диләр, Шүрәле.

Табигатнең матурлыгын

Безгә килеп күр әле...

9 нчы укучы.

Елга-күлләр көмеш сулы-

Ятып эчәргә ярый.

Басма өстендә Су анасы

Алтын чәчләрен тарый.

10 нчы укучы.

Язлары ләйсән яңгырлы,

Җәйләргә кояш патша.

Гәрәбәдәй басу-кырлар

Алтын көзгә тоташа.

11 нче укучы.

Аяз күктән мәрҗән булып

Йолдызлары коела.

Туган якның һавасы да

Шифалырак тоела.

(Шигырьләрен сөйләп бетергәч укучылар утыралар)

Сезнең игътибарыгызга Татар халык биюе. Башкаралар бию түгәрәгенә йөрүче укучылар.

1 нче алып баручы.

Фәүзия апа - лирик хисләр җырчысы. Аның шигырьләре көйгә салынганчы ук җырлап торалар. Шигырьләренә җирле композиторыбыз көй язып, матур җырлар туа. Иҗат иткән җырларның күбесен танылган җырчылар башкара һәм ул җырларны инде Татарстанда гына түгел, татарлар яшәгән чит төбәкләрдә дә бик яратып тыңлыйлар. “Галиҗәнап Нурлат икмәге”, “Шәфкать туташы”, “Ут янып тора миләш”, “Якты Күлем”, “Өмет”, “Мәхәббәт турында” һ.б. җырлары авторга иҗат дөньясында зур популярлык китерде. Бөтен татар дөньясына билгеле булган “Чияләр” җырын Фәүзия апаның визит карточкасы дияргә була.

Җыр “Чияләр” Башкара мәктәбебезнең сандугачы.

1 нче алып баручы.

Кояшка һәм айга гашыйк

Җир кызы булып үстем

Бар теләгем – җиңү иде

Җирнең бу тату көчен

Бар хыялым - очу иде

Киек каз юлларыннан

Гомерем буе аерылмадым

Йолдызлы уйларымнан.

Әле һаман өметләнәм

Болытларны кочарга

Шигъриятне канат итеп

Талпынамын очарга! -дип яза Фәүзия апа үзенең шигырендә.

2 нче алып баручы.

Фәүзия апа!

Сез җирдәге һәр нәрсәгә гашыйк,

Гашыйк таңга, зәңгәр кичләргә.

Сез яшисез шундый матурлыкка,

Тагын бер матур ямь өстәргә.

1 нче алып баручы.

Хәзер сүзне сезгә бирәбез. Бәлки безгә үзегезнең шигырьләрегезне укырсыз яисә әйтәсе киңәшләрегез бардыр.

Рәхим итегез.

Сораулар.

1. Беренче шигырьләрегезне хәтерлисезме?
2. Шигырь язу таланты кемнән бирелгән?
3. "Ак калфак" оешмасы турында берничә сүз әйтеп китмәсез микән?
4. Соңгы вакытта нинди темаларга мәдхия җырлыйсыз?
5. Яңа гына басылып чыккан китабыгыз турында берничә сүз әйтеп китмәсез микән.

1 нче алып баручы.

Татар халык биюе. Башкаралар бию түгәрәгенә йөрүче укучылар.

Кадерле балалар, укытучылар! Безнең өчен кадерле булган, җирле шагыйребез Ф. Мөхәммәтова – белән очрашу кичәсе ахырына якынлаша. Бик зур рәхмәт сезгә. Укучыларыбыз сезгә дә бүләкләр әзерләделәр. Шул бүләкләрне тапшырырга рөхсәт итегез.

Без Фәүзия апага иң изге теләкләребезне юллыйбыз һәм шагыйрәбезнең үзенә генә тәңгәл килгән шигъри юлларып әйтеп калырга ашыгабыз!

"Шигърият иле" кояш күпере,
һәм шул күпергә кергәннән башлап,
Яшьлек илендә кала белеп син
Үз яшьлегеңне яшисең саклап

2 нче алып баручы.

Кергәннән бирле серле, сихерле,

Озын гомерле кояш иленә,

Ут – кояш кызы диеп үзеңә

Ихлас күңелдән әйтәбез, менә .....

1 нче алып баручы.

Сүзне Район мәгариф идарәсенең милли мәсьәләләр буенча методисты Ярмөхәммәтова Фәридә Минталип кызына бирәбез.

Сүзне уку – укыту эшләре буенча директор урынбасары Шарапова Наилә Таһирҗан кызына бирәбез.

1 нче алып баручы.

Кадерле кунаклар! Безнең кичәбез ахырына якынлашты. Игътибарыгыз өчен бик зур рәхмәт. Барыгызга да саулык – сәламәтлек, уңышлар теләп бәйрәмебезне Фәүзия Мөхәммәтова сүзләренә иҗат иткән җыр белән тәмамлыйбыз.